# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы**
**Баулы муниципаль районы**
**Яңа Зареченск авыл җирлегенең**
**Яңа Зареченск торак пунктында**

2021 нче елның 16нчы декабрь № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлегенең Яңа Зареченск торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1нче төркем инвалидлардан, 75тән өлкәнрәк яшьтәге ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2022 елда 300 сум күләмендә үзсалым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Яңа Зареченск поселогында урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү (терәкләр урнаштыру, ремонт, урам утларын алыштыру);
- Кышкы чорда Яңа Зареченск поселогында юлларны карап тоту (кардан чистарту);
- Яңа Зареченск авылы зиратын төзекләндерү (койма ремонты).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яна Зареченск авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зәбирова